| | | |
|---|---|---|
| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.12.2024 № 702-П

Татарстан Республикасы, Арча районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча эзләп табылган «Ш. Мәрҗанинең эти-әнисе кабер ташы» мәдәни мирас объектын, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең эти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты сыйфатында, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертү, мәдәни мирас объектының сак предметын билгеләү, чикләрен раслау турында

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы Федераль законы, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы Татарстан Республикасы Законы, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2024 елның 7 нче декабренә караган уңай бәяләмәсенә нигезләнеп боерам:

1. Татарстан Республикасы, Арча районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча эзләп табылган «Ш. Мәрҗанинең эти-әнисе кабер ташы» мәдәни мирас объектын, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең эти-әнисе кабер ташы» (объект төре - һәйкәл) төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты сыйфатында, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертергә.

2. Әлеге боерыкка караган 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш.

Мәрҗанинең әти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга.

3. Әлеге боерыкка караган 2 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең әти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының сак предметын расларга.

4. Мәдәни мирас объектларын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген исәпкә алу бүлегенә, күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

5. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.


Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2024 елның
23 нче декабрендәге 702-П
номерлы боерыгына
караган 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең әти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты

**территориясе чикләре**

Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең әти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картасы (схемасы)




Масштабы 1:1000

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| ① | - мәдәни мирас объекты |
| 2• | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| | - мәдәни мирас объекты территориясе |
| | - БДКМР белешмәләре буенча җир кишәрлекләре чикләре |
| 16:09:240401:255 | - җир кишәрлегенең кадастр номеры |

Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең әти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең текст тасвирламасы

Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең әти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәге урыннардан уза

| Чикнең узу урыны | | Чикнең узу урынының тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктадан | |
| 1 | 2 | 1 нче ноктадан 12,49 м ераклыкта, төньяк-көнчыгыш юнәлештә 2 нче ноктага кадәр |
| 2 | 3 | 2 нче ноктадан 13,50 м ераклыкта, көньяк-көнчыгыш юнәлештә 3 нче ноктага кадәр |
| 3 | 4 | 3 нче ноктадан 12,49 м ераклыкта, көньяк-көнбатыш юнәлештә 4 нче ноктага кадәр |
| 4 | 1 | 4 нче ноктадан 13,50 м ераклыкта, төньяк-көнбатыш юнәлештә 1 нче ноктага кадәр |

Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең әти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы нокталар таблицасы

| № | Җирле координаталар системасында характерлы нокталарның координаталары (ҖКС-16) | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 1 | 537624.86 | 1341944.88 |
| 2 | 537633.43 | 1341953.97 |
| 3 | 537623.61 | 1341963.23 |
| 4 | 537615.04 | 1341954.14 |
| 1 | 537624.86 | 1341944.88 |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2024 елның
23 нче декабрендәге 702-П
номерлы боерыгына
караган 2 нче кушымта


Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең әти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының
**сак предметы***

Мәдәни мирас объектының сак предметы булып:

1. Объектның урнашу урыны: Ташкичү авылы зиратының үзәк өлеше.
2. Күләм-киңлек композициясе: ярымтүгәрәк сызыклы ялгыз кабер ташы (плитә). Кабер ташының габаритлары.
3. Таш техникасы һәм материаллары: известьташ; кисү.
4. Язулар һәм текстлар, аларны башкару техникасы: ташның яклары һәм кырыйлары Ш.Мәрҗани тарафыннан гарәп телендә куфи хәрефе белән рельефлы текст белән язылган; техника (кисеп алу, гравировка).

* Комплекслы фәнни тикшеренүләр һәм реставрация эшләрен башкару барышында сак предметы өстәлергә мөмкин.

Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Ташкичү авылы, зират адресы буенча урнашкан «Ш. Мәрҗанинең әти-әнисе кабер ташы» төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының сак предметы таблицасы

| | **Сак предметы** | **Төп элементларны фотофиксацияләү/график материаллар** |
|---|---|---|
| 1. | Объектның урнашу урыны: Ташкичү авылы зиратының үзәк өлеше. |   1 нче рәсем. Объектның урнашу урыны |
| 2. | Күләм-киңлек композициясе: ярымтүгәрәк сызыклы ялгыз кабер ташы (плитә). Кабер ташының габаритлары. |  2 нче рәсем. Көньяк-көнчыгыш ягыннан күренеш |

| | | |
|---|---|---|
| | |  3 нче рәсем.  Төньяк-көнчыгыш ягыннан күренеш |
| 3. | Таш техникасы һәм материаллары: известьташ; кисү.<br>4. |  3 нче рәсем. Көнбатыш яктан күренеш |
| 4. | Язулар һәм текстлар, аларны башкару техникасы: ташның яклары һәм кырыйлары Ш.Мәрҗани тарафыннан гарәп телендә куфи хәрефе белән рельефлы текст белән язылган; техника (кисеп алу, гравировка). |  4 нче рәсем. Язулар |